


# Тамчы

«2 нче санлы Җәлил урта мәктәбе» газетасы

апрель №10 (70) 2016-2017 нче уку елы


# Тукай айлыгында - «Экология атнасы»

## Редактор сүзе

**2017 нче ел Президент Владимир Путин Карары нигезендә, Россиядә Экология елы дип игълан ителде, ул бу хактагы Указга кул куйды.**

Укучылар һәм укытучыларыбыз Җир турынданиләр уйлыйлар икән? Халыкара Җир көне уңаеннан без сораштыру үткәрдек. Кайбер җавапларны укыгыз әле.



Һәркем Җир чисталыгы турында уйланырга, кайгыртырга тиеш. Әгәр без бүген планетабызны чүптән арындырмыйбыз икән, ул 10 елдан аны 5 метр биеклектә каплап китә ала икән! Сак булырга кирәк.

**Л.К. Шәйдуллина**



Җир безнең уртак йортыбыз. Монда минем туган илем. Мин яшәвемә куанам. Агачлар утыртып, чәчәкләр үстереп, чисталыкны саклап яшәргә кирәк. Ул вакытта планетабыз бик матур булачак.

**Э. Миназева**

Җир – мин яшәгән, укыган урын. Яхшы итеп укырга, шәп итеп яшәргә кирәк!

**А.Идрисов**



Минем өчен иң кадерле кешеләр: әтием,әнием, энем, туганнарым, дусларым. Алар да Җирдә яшиләр. Миңа яшәү кадерле. Димәк, Җир дә!

**Д. Насыйбуллин**

## Экологик кичәдә

**Атналык 5 нче сыйныфлар өчен әзерләнгән “Экологик кичә”дән башланды. Аны татар теле укытучысы Л.Ф.Ихсанова белән математика фәне укытучысы Л.Ф.Евстафьева үткәрделәр. Укучылар экологик проблемаларга багышланган проектларын якладылар, бәхәсләштеләр, фикер алыштылар.**

## Экологик театр

**Сәлимҗанова А.И. укучылары берничә сыйныф укучыларын “Сәламәтлек театры” тамашасына дәштеләр. Тамаша барышында укучыларга дөрес туклану, табигать законнарын үтәп яшәү турында бик үтемле киңәшләр бирелде.**

## Экология дәресләре

Атналык экология дәресләренә бай булды. Аларны сыйныф җитәкчеләре, табигать белеме белән бәйле предметларны берләштерүче методик берләшмә укытучылары да, өлкән сыйныф укучылары да үткәрде. 9 нчы сыйныф укучылары Кәримова Г. Һәм Бакирова Э.үзләренең чыгышларын Г.Ахуновның “Хәзинә” романы белән бәйләделәр. Алар яшьтәшләрен хәзинәбезнең кара алтын гына түгел, ә тирә-як мохит тә булуын, аны саклап яшәргә кирәклеген әсәрләр эчтәлеге аша җиткерергә тырыштылар.

## Экологик күргәзмә


Атналык барышында “Янәшәбездә - яшел аптека” дип исемләнгән макетлар күргәзмәсе эшләде. Экологик проблемалар турында сөйләүче проектлар, стена газеталары чыгарылды.

## “Экология атналыгы”ннан фоторепортаж














21 нче апрель көнне Казанда татар теленнән V Халыкара олимпиаданың йомгаклау тантанасын үз эченә алган “Туган тел” форумы булды. Анда районыбызның татар теле укытучылары катнашты. Районыбыз данын яклаучылар арасында мәктәбебезнең 9 а сыйныфы укучысы Әлмиева Резедә дә бар иде. Резедә Тукай-Кырлайда, Камал театрында булуы, әллә ничә төбәктән, чит иллләрдән килгән милләттәшләребез белән иркенләп татарча сөйләшеп, аралашып, яңа дуслар табып кайтуы белән бәхетле булуын әйтте



**Шеф редактор**: Шайдуллина Ландыш Камил кызы
Редколлегиядә: Зәкиева Азалия, Мөхәмәтгалиева Гүзәл, Насыйбуллин Данияр (6-в)